**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Югары Татар Майнасы торак пунктында 2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2022 елның 27 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Югары Татар Майнасы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге Югары Татар Майнасы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Авыл эчендәге юлларга таш җәю һәм төзекләндерү;
2) Җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
3) Су манарасы өчен су насосын сатып алу һәм өлешчә сууткәргечне алыштыру;
4) торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту ( урам утлары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
5) ДПО ны ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Майна авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Майна авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майна авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы В.В. Горбунов